Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Троицкий авыл Советы

КАРАР

12 май 2025 ел № 119

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2025 елның 06 мартындагы 02-01-24 номерлы протестын карап

Яңа Троицкий авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 85 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 125 номерлы , 2015 елның 05 маендагы 146 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 126 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 91 номерлы, 2024 елның 16 июлендәге 102 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;

-Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш»;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Троицкий авылы, Совет урамы, 10 йорт, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1 нче йорты торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Троицкий авыл
җирлеге башлыгы Л.И. Горбунова